РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.08.2019 Олы Кайбыч авылы № 48

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль җирлегендә 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны уздыру буенча Комиссия төзү турында

РФ Хөкүмәтенең 2017 елның 29 сентябрендә чыккан 1185 номерлы «2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте комиссиясен төзү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 15августында чыккан 682 номерлы «2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча комиссия төзү турында» карарына ярашлы итеп, «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җирле үзидарә органнары гамәлләрен координацияләү һәм килешеп эшләүне тәэмин итү максатларында, карар бирәм:

1. «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Комиссия төзергә.

2. Расларга:

«Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Комиссиясе турында Нигезләмәне;

«Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Комиссия составын.

3. «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

3.1. 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча комиссия төзүне.

3.2. Адреслар исемлекләрен актуальләштерү һәм оештыру планнарын төзү өчен, 2019 елның 1 сентябренә кадәр, билгеләнгән тәртиптә, Дәүләт статистикасы

органнарына шәһәр һәм авыл торак пунктларында төзелеш төрен (торак яки торак булмаган) һәм балансында әлеге төзелеш булган оешманың, предприятиенең исемен күрсәтеп, торак биналар һәм яшәү яисә хәзер булу урыны буенча биналарда яшәүче һәм теркәлгән затлар саны турында белешмәләр тапшыруны;

3.3. 2019 елның 1 сентябренә кадәр муниципаль берәмлекләрдә йорт номерлары һәм фатир номерлары белән күрсәткечләр булуны тәэмин итүне.

4. «Кайбицкие зори» («Кайбыч таннары») район газетасына Кайбыч муниципаль районындагы Дәүләт статистикасы органнары белгечләренә 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуның максатларын, бурычларын һәм әһәмиятен тәэмин итүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-аңлату эшләре алып баруда ярдәм итәргә тәкъдим итәргә.

5. «Кайбыч муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә 2020 елда халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә теркәлгән эшсез һәм мәшгуль булмаган гражданнарны Бөтенроссия халык санын алуны үткәрүгә җәлеп итүгә булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының 30.05.2008 чыккан 30 номерлы «2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алу» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый-мәгълүматый рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.И.Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының
«22» август 2019 е. № 48
номерлы карарына Кушымта №1

«Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Комиссиясе турында Нигезләмә

1. Кайбыч муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү Комиссиясе (алга таба - Комиссия) «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләрен оператив хәл итү һәм җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен координацияләү һәм тәэмин итү өчен төзелде.

2. 2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, 2002 елның 25 гыйнварындагы «Бөтенроссия халык санын алу турында» 8-ФЗ номерлы Федераль законга, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, Кайбыч муниципаль районының норматив-хокукый актларына, Татарстан Республикасында 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү Комиссиясе турындагы Нигезләмәгә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссиянең төп бурычлары:

«Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү, үткәрү буенча җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү;

Кайбыч муниципаль районында 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү.

4. Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен Комиссия:

Кайбыч муниципаль районында 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү барышын контрольдә тота;

Кайбыч муниципаль районында 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуга әзерлек һәм аның оператив нәтиҗәләре турындагы сорауны карый;

Кайбыч муниципаль районында 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрүнең оештыру планынраслый;

түбәндәге сораулар буенча тәкъдимнәрне карый:

Кайбыч муниципаль районында 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү эшенә төрле оештыру-хокукый формадагы оешмаларны җәлеп итү;

тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче гражданнарны халык турында мәгълүмат җыюга, шулай ук халык турында мәгълүматларны эшкәртүгә җәлеп итүне оештыру;

Кайбыч муниципаль районында 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру:

халык турында мәгълүмат җыюга җәлеп ителгән затларны өйрәтү һәм эшләү өчен яраклы булган җиһазлар һәм элемтә чаралары белән тәэмин итү;

2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алу кәгазьләрен һәм башка документларны саклау өчен саклана торган биналар белән тәэмин итү;

2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү өчен кирәкле транспорт чаралары, элемтә чаралары белән тәэмин итү;

2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү өчен кирәк булган картографик материалларны (авыл җирлекләре схематик планнарын) төгәлләштерү;

2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү эшләрен уздыру өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрен җәлеп итү, шул исәптән Интернет аша халык санын алуда катнашу өчен Дәүләти хезмәтләренең бердәм порталына керү мөмкинлеген бирү;

2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуда халык турында мәгълүмат җыючы затларның иминлеген, исәпкә алу кәгазьләренең һәм башка документларының сакланганлыгын тәэмин итүне оештыру;

гражданнарның ябык торак комплексларына, коммерцияле булмаган яшелчәчелек берләшмәләре территорияләренә керүләрен тәэмин итүне оештыру һәм башкалар;

2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуга кагылышлы басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус җиһазландырылган урыннар бирү;

Интернет челтәрендә Дәүләти хезмәтләрнең бердәм порталында җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен халык санын алуда катнашуга җәлеп итү;

шәһәр һәм авыл торак пунктларында торак һәм торак булмаган фонд йортлары буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелеш төрен (торак яки торак булмаган) һәм балансында төзелеш булган оешма, предприятие исемен күрсәтеп, мәгълүмат бирү;

яшәү урыны буенча яки хәзер булу урыны буенча торак урыннарында

яшәүче һәм теркәлгән затларның саны һәм адреслары исемлекләрен актуальләштерү һәм оештыру планнарын төзү өчен яшәү урыны буенча яшәүче һәм теркәлгән затларның саны турында мәгълүмат бирү;

2002 елның 25 гыйнварындагы «Бөтенроссия халык санын алу турында» 8-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 пункты нигезендә, торак, торак-эксплуатация оешмалары, идарәче оешмалар һәм компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак-төзелеш кооперативлары белән идарә итү органнары турында яшәү урыны һәм хәзер булу урыны буенча теркәлгән затлар турында административ мәгълүмат бирү;

вазыйфаи затлары дәүләт, муниципаль һәм шәхси торак фондының торак урыннары буенча халыкны теркәү исәбен алып бара торган җирле үзидарә органнары тарафыннан (һәр фатирлы карточкалар, йорт (фатир) китаплары) мәгълүмат бирү;

2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуга әзерләнү һәм аны үткәрү вакытында Кайбыч муниципаль районы территориясендә мәгълүмати-аңлату эшләре үткәрүне оештыру;

2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуга әзерләнүдә һәм аны үткәрүдә актив катнашкан физик һәм юридик затларны бүләкләүне оештыру.

5. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

үз утырышларында 2020 елдагы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү барышы турында федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләре мәгълүматын тыңларга;

Комиссия эшенә билгеләнгән тәртиптә Кайбыч муниципаль районы буенча федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, фәнни, иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар вәкилләрен, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итәргә;

Комиссиягә йөкләнгән бурычларны хәл итүгә бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү өчен эшче төркемнәр булдырырга.

6. Комиссия Комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, Комиссия әгъзаларыннан һәм сәркатиптән тора.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Комиссия утырышларының еллык планнарын раслый һәм Комиссия составын яңарту турында тәкъдимнәр кертә, утырышларны алып бара.

Комиссия рәисе булмаган вакытта яисә аның кушуы буенча Комиссия рәисе
вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия утырышлары зарур булган саен үткәрелә, ләкин ярты елга бер тапкырдан да ким түгел, 2020 елда – еллык эш планнары нигезендә, 3 тапкыр үткәрелә. Комиссия утырышы анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашкан очракта, тулы хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары аның утырышларында алыштыру хокукыннан башка катнашалар.

Комиссия әгъзалары һәм чакырылганнар докладлар һәм өстәмә докладлар белән чыгыш ясый, фикер алышуларда тәкъдимнәр кертә, тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы буенча белешмәләр бирә ала.

Комиссия утырышларын тиешле мәгълүмат бирүчеләргә язып аудио - һәм видеоконференцияләр режимында үткәрергә мөмкин.

8. Комиссия карарлары Комиссия утырышында катнашкан әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карарлары, утырышта рәислек итүче Комиссия рәисе яисә аның урынбасары имза сала торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

«Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы карарын таләп итүче мәсьәләләр буенча Комиссия билгеләнгән тәртиптә тиешле тәкъдимнәр кертә.

9. Комиссиянең аның компетенциясе кысаларында кабул ителгән карарлары Кайбыч муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында 2020 елгы Бөтенроссия халык

санын алуны әзерләүгә һәм үткәрүгә ярдәм итү максатларында төзелгән комиссияләр өчен мәҗбүри булып тора.

10. Комиссия эшчәнлеген туктату турындагы карар «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы тарафыннан кабул ителә.

11. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Кайбыч муниципаль районында дәүләт статистикасы органнары белгечләре тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының
«22» август 2019 е.№48
номерлы карарына Кашымта №2

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы»
муниципаль җирлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык
санын алуга зерлеккә һәм уздыруга ярдәм күрсәтү Комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Рәхмәтуллин Альберт Илгизәр улы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы – комиссия рәисе |
| Хәялиев Рәмис Рафис улы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасары – комиссия рәисе урынбасары |
| Макаров Алексей Николай улы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе- комиссия рәисе урынбасары |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Заһидуллина Эльвира Хәсбәтулла кызы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Камалетдинов Радик Мәҗит улы | Татарстан Республикасы АХһАМның Кайбыч районында АХһАИ Башлыгы (килешү буенча) |
| Бәдертдинова Дания Әкраметдин кызы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче |
| Хуҗин Рушан Галимулла улы | Кайбыч муниципаль районыРоссия ЭЭМның ТР кайбыч районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Камалиева Эльвира Рафис кызы | Кайбыч районы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ДБУ директоры (килешү буенча) |
| Канашов Игорь Геннадий улы | “Таттелеком” ААҖнең Буа ЗУЭСының Кайбыч РУЭСы башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмидуллин Илмас Илдар улы | “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кайбыч муниципаль районының мәгариф бүлеге” МКУ башлыгы |
| Михайлова Ландыш Гаделҗан кызы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Гибадуллина Наилә Наил кызы | “Федераль кадастр палатасы Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте” |

| | |
|---|---|
| | Федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлегенең 3нче филиалы башлыгы (килешү буенча) |
| Сөнгатуллина Луиза Мәгыйс кызы | “Кайбицкие зори”(Кайбыч таннары) газетасы баш мөхәррире (килешү буенча). |
| Җамалетдинова Фәрдия Якут кызы | Территориаль ТР буенча федераль дәүләт статистикасы хезмәте органы әйдәп баручы белгеч-эксперты (килешү буенча). |
| Камалиева Чулпан Әнвәр кызы | “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУсе ЗАГС бүлеге башлыгы |
| Мифтахова Римма Гарифҗан кызы | «АК БАРС Страхование»ҖЧҖ Кайбыч операцион офисы директоры (килешү буенча) |
| Чекмарев Федор Александ улы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Зур Подберезье авыл җирлеге Башлыгы (килешү буенча) |
| Сафина Лилия Рәшит кызы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башлыгы (килешү буенча) |
| Тараканов Петр Петр улы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге Башлыгы (килешү буенча) |
| Нигъмәтҗанов Фидаил Тәлгать улы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Башлыгы (килешү буенча) |